ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

25.10,2021 п.г.т.Алексеевское № 389

2022 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә нигезендә

карар бирәм:

1. 2022 елга расларга:

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар (Кушымта);

сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы (Леденцов О. Н.) әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы **А.В.Симашева**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 25 октябрендәге
389 номерлы карарына
кушымта

Алексеевск муниципаль районының эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше	Территориаль дислокация	Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сум)				
		өч еллык укыту срогы	дүрт еллык укыту срогы	биш еллык укыту срогы	җиде еллык укыту срогы	иртә һөнәри юнәлеш бирү
Музыкаль сәнгать	шәһәр җирлеге			55 793	64 719	84 130
	авыл җирлеге			60 519	70 105	90 982
Нәфис сәнгать	шәһәр җирлеге		30 808		26 803	64 347
	авыл җирлеге		33 235		28 980	69 559
Хореографик сәнгать	шәһәр җирлеге			58 474	48 228	175 835
	авыл җирлеге			63 795	52 609	191 884
Гомуми эстетик сәнгать	шәһәр җирлеге			25 592		
	авыл җирлеге			27 818		
Фольклор сәнгате	шәһәр җирлеге			55 174	52 945	85 700
	авыл җирлеге			60 079	57 660	93 239
Эстрад-джаз сәнгате	шәһәр җирлеге	84 971		81 330		134 297
	авыл җирлеге	92 265		88 340		145 742
Театраль сәнгать	шәһәр җирлеге	43 848		40 718	40 728	64 463
	авыл җирлеге	47 585		44 206	44 213	69 610